Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Советы

# КАРАРЫ

“06” апрель 2026 ел № 20

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указының 4 пунктын үтәү максатыннан Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- “Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында” нигезләмәне раслау хакында 2017 елның 31 июлендәге 50 номерлы карарын;
- “Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” 2018 елның 21 ноябрендәге 83 номерлы карарын;
- “Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” 2019 елның 20 ноябрендәге 114 номерлы карарын;
- “Санлы финанс активлары һәм санлы хокуклар турында мәгълүматлар тапшыру һәм Күңгәр авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2021 елның 21 июлендәге 28 номерлы карарын;
- “Күңгәр авыл җирлеге Советының 2017 елның 31 июлендәге 50 номерлы «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында»гы нигезләмәне раслау хакындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2023 елның 30 июнендәге 78 номерлы карарын;
- “Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” 2024 елның 28 маендагы 100 номерлы карарын;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Рәхимҗанова Г.И.